СӨЙ ГОМЕРҺЕ, СӨЙ ХАЛЫҚҺЫ, СӨЙ ХАЛЫҚҺЫҢ ДӨҢЬЯСЫҺ!

ДУСЛЫҚ

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

8 октябрь, 1997ел.
ҮӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 113 (8125) | Бәясе билгеләнгәнчә

КӨЗГЕ КӨННӘР АШЫКТЫРА

«Уңыш - 97» бәйрәменә хәзерләнеп

4 октябрьдә район хакимияте бинасының кече залында шәһәр оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре катнашында «Уңыш - 97» бәйрәменә әзерлек буенча киңәшмә үтте. Аны хакимият башлыгының социаль - мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Р.Ногъманова алып барды. Ул сабантуй мәйданында җәеләчәк чаралар планын җентекләп аңлатты, җитәкчеләр алдына бәйрәмгә лаеклы вәкиллек әзерләү бурычы куйды. Аннан соң Норлат җирле үзидарә Советы рәисе Р.Г.Билалов сүз алды. Ул бәйрәм алдыннан шәһәрне җыю, төзекләндерү, җәмәгать урыннарында тиешле тәртип булдыру мәсьәләләренә тукталды, хезмәт коллективларын бәйрәмне спонсорларга чакырды.

Киңәшмәдә хакимият башлыгы аппарат җитәкчесе Ф.М.Галимов катнашты һәм чыгыш ясады.

АЛДЫНГЫЛАРНЫ КАЗАН КӨТӘ

Сүз 10 октябрь көнне башкалабыз Казанда үтәчәк республика Уңыш бәйрәме турында бара. Җөмһүриятебезнең кыр батырларын җыячак бу зур тантанада, республика амбарларына 86271 тонна ашлык озатучы, 53017 тонна ашамлык бодае сатучы Октябрь районының лаеклы вәкилләре буларак 27 вәкил катнашачак. Алар нигездә Октябрь җирендә мул уңыш үстерүдә турыдан - туры катнашы булган кешеләр: игенчеләр, хуҗалык җитәкчеләре, АПК составындагы эшкәртү промышленносте хуҗалары, авыл хуҗалыгына шефлык итүче оешма - предприятие җитәкчеләре. Бу тантанада «ДОН - 1500»дә 40150 центнер ашлык суктырып, район игенчеләре арасындагы бәйгене җитәкләгән Р.К.Насыйбуллин («Алга» КХАсы), куәтле «Кейс»ны буйсындырып, район кырларын иңләгән В.В.Булатов (МТС), «Нива» белән дә 21 мең центнердан артык ашлык җыеп алган И.В.Николаев (Мичурин исем.КК), «Полесье»да 453 гектар азык культуралары урдырган В.В. Глушкин (МТС), элеваторга 3890 тонна ашлык күчергән шофер Н.Д. Шпаров (АТП), тракторчы Ә.М.Гыйниятуллин (Хафизов исем. КХА) да бар. Яңа оешкан «Мәскәү», «Таң» кооперативлар ассоциацияләре җитәкчеләре В.Н.Сайкин, Р.Х.Фәхретдинов та аннан үзләре өчен яңалыклар алып кайтырлар дип уйлыйбыз. Ә инде үз басуларында тотрыклы уңыш үстереп дан алган Мичурин исемендәге КК рәисе И.Н.Мөхәммәтов (уртача уңыш 60 центнер), Хафизов исемендәге КХА рәисе В.Ф.Булатов (41,0 центнер), «Рассвет» совхозы рәисе Х.Н.Атауллин (56,7 центнер), «Кондырча» рәисе И.Г.Әхмәтсафин (61 центнер) һәм башкалар бу көнне үз адресларына һичшиксез мактау сүзләре ишетми калмаслар. Хәер, Октябрь җирендә, шул исәптән кырларында да башланган «революция»нең алгы сафында атлаучы алдынгыларыбызның тантанада күкрәк киереп кунак булырга хаклары бар. Ә Сез, хөрмәтле газета укучылар, бу тантананың трансляциясен «Татарстан» телеканалыннан 10 октябрь көнне 20 сәг.тә кararга онытмагыз. Хезмәт сөючән якташларыбыз өчен тагы бер кат горурланыйк әле!

С.НУРУЛЛИНА.

Виктор Федотович Булатов исемен Хафизов исемендәге КХА да аеруча бер җылылык, хөрмәт белән атыйлар. Гомерә буе шушы хуҗалыкта эшләп, фидакарь хезмәте, ипле, акыллы холкы белән яулаган хөрмәт бу. Эшендә генә түгел, гаиләсендә дә иплелек, татулыкка ирешә алуы белән дә. Иң шатлыклысы - Булатов яшәү кыйбласы, тормыш мәгънәсе иткән бөек миссиясе - җиргә хезмәт итүен дәвам итә. Аның Т - 150 тракторына хуҗалыкта бер дә эш бетеп тормый. Көзен ул хезмәтнең иң җаваплы участогында җирләрне туңга сөрү белән мәшгуль. Район сөрүчеләр конкурсында хуҗалык данын яклап чыгыш ясаган Булатов, әлбәттә, туган кырлары туфрагын эшкәрткәндә һич тел - теш тидерерлек эшләми: смена нормасын арттырып үти, югары сыйфат та тәэмин итә.

Рәсемдә: Хафизов исем. КХА механизаторы В.Ф.Булатов.

Бар эштә дә уңган

Михаил Петрович Ивашкин - Хафизов исемендәге хуҗалыкның бар эшкә дә уңган механизаторларыннан берсе. Киң профильле механизатор яз көне инде тарала язган тракторны сафка бастырып терлекчелек фермалары тирәсендәге тиресләрне җыештырды. Аннан соң аңа «ДОН - 1500» комбайнын ремонтларга куштылар. Шуның белән шактый гына мәйданнарда игеннәрне суктырып алды ул. Анысын саклауга урнаштыру белән Михаил Петрович КС- 6 чөгендер алу комбайнын ремонтларга кереште һәм хуҗалыктагы татлы тамыр плантацияләренең берсендә аның агрегаты эшли. Уңган механизатор бу җаваплы эштә дә сынатмый.

Т.Дербышев, хәбәрче.

● Икенче урак бара

ТАРҚАУ «КОМБАЙН» КЫРДА ТАРАЛА

Заманында һәр эшне дә яннан ярдәм кертмичә мөстәкыйль башкара торган «Комбайн» КХАсында соңгы елларда бер генә мөһим авыл хуҗалыгы кампаниясе дә чит - ятлар булышлыгыннан башка бармый. Шикәр чөгендерен мисалга алыйк. Быел аны 180 гектар мәйданга чәчкәннәр. Авылдагы һәркем - производствода эшләүче хатын - кызлар (ә алар бармак белән генә санарлык), мәктәп, бухгалтерия, җирле үзидарә Советы хезмәткәрләре, хәлләреннән килгәнчә пенсионерлар да эшкәрткән аны, әмма шәһәрләләр - дәүләт салым инспекциясе, госстрах, дәүләт санэпидкүзәтү үзәге, шефлар - ДРСУ хезмәткәрләре әлешенә төшкәне дә аз булмаган.

Инде шикәр чөгендере казыту чоры җиткәч тә, зур авырлык белән башлаганнар аны биредә. Иң әлек, техника белән тоткарлык туган. Елның - елында шикәр чөгендере казыту белән мәшгуль булган өч агрегат - комплексны көч - хәл белән төзәтеп, басуда йөрерлек хәлгә китергәннәр китерүен. Әмма янә чатаклык: эш БМ - 6 яфрак урдыру комбайннарын тагып йөрерлек тракторлар булмау белән янә тоткарланган. Югыйсә, хуҗалыкта бу эшне башкарырлык Т - 70 тракторлары да дүртәү. Әмма... алдан хәзерлек күрелмәү сәбәпле, сезон башына аларның барысы да ярым җимерек була. Әмзәләләр беренче буразна чөгендерне казыткан районның байтак хуҗалыклары ун көнләп эшләп, шактый мәйданда плантацияләр уңышын җыеп, аны дәүләткә озатып яталар иде инде.

Хәер, «Комбайн»да шул көннән алып та эш гөрләп китте дип әйтеп булмый. Чөгендер казыту, яфрак урдыру комбайннарының ватылмаган көне сирәк. Югыйсә, басуда егетләрнең дә сер бирә торганнары эшләми. Әнә, җирле үзидарә Советы рәисе Әүхәт Галимов, танылган механизаторлар Әдип Асылханов, Тәлгать Мәсгутов, пенсионер Вәкил Гатин, өметле күренүче яшь кадрлар - Николай Казаков, Риназ Мотаһиров барысы да тырышалар. Алар никадәр генә көч түксәләр дә, ашык - пошык төзәтелгән техника белән әллә ни зур эш майтара алмаулары көн кебек ачык. Шуңа да 7 октябрьгә хуҗалык буенча шикәр чөгендеренең уңышы җыелган мәйданнары 28 (район буенча 48) процент кына тәшкил итте. Шушы көнгә хуҗалык шикәр заводына нибары 201 тонна (задание 2.700 тонна) продукция озаткан иде.

Гомумән, «Комбайн»да булу күңелдә авыр, борчулы хис тудырды. Күктә кара - кучкыл болытлар йөзүе, диңгездәй җәйрәп ятучы яшел чөгендер кыры, «елап» торучы, кем әйтмешли, кашын җыерган салкын көндә кагатлар янында күшеккән кулларын сулышлары белән җылытып чөгендер кисүче хатын - кызлар һәм... ташбакадай хәрәкәт итүче техника... Зар өстенә зар: узган елның октябрендә соңгы тапкыр 50 - 70әр мең сум хезмәт хакы алу, хезмәт кешесенә игътибар, хөрмәт булмау, хуҗалык җитәкчелегенең тупаслыгы, авылның киләчәгә булмауга һафалану... Җитәкчеләр, белгечләрнең аклану сәбәпләрен көне буена да тыңлап бетерерлек түгел. Гаепнең авыр башы шефлар - ДРСУга төшә: санга сукмыйлар. Бу җәһәттән без үз чиратыбызда идарә җитәкчелеге белән телефон аша элемтәгә кердек.

- Яздан әлеге хуҗалыкка 500 миллион сумлык ярдәм күрсәттек. Бер генә тиенебезне дә кире ала алмадык. Бүген берәр К - 700, Т - 150 тракторлары бызы эшли Әмзәдә. Кулдан килгәнчә чөгендер чистартырга да булышабыз. Автотранспортыбыз исә район хакимияте башлыгы карары нигезендә «Үрнәк» хуҗалыгыннан йөк ташый,- диде безгә ДРСУ начальнигы Р.А.Газизуллин.

Гомумән, ике арада аңлашылмаучанлык бар. Ә ул, безгә калса, Ә.В.Мөлеков «Комбайн»да түгел, ә ДРСУ белән җитәкчелек иткәндә башланган иде инде.

... Ышанабыз, акрынлап булса да барыр Әмзәдә эш. Әмма сүз уңаенда, биредә хезмәт җимешләре дә әлләни мулдан булырга охшамавын да билгелисе килә. Җәен, әлеге дә баягы, техника булмау сәбәпле зур «игътибар» күрмәгән шактый мәйданнарына боз суккан плантацияләрдә чөгендер дә әлләни үсә алмаган. Хуҗалыкта яфрак чистартып бетергәч агрегат булмау сәбәпле, хәзер хатын - кызларга аларның һәрберсен кул аша үткәрергә кирәк була.

Гомумән, Әмзәдә шундый хәлләр. Шәптән түгел алар.

Р.ГИНЯЕВА.

Депутатлар игътибарына!

1997 елның 3 нче октябрендә халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы утырышы булып үтте. Анда халык депутатларының Октябрь район Советының чираттагы уникенче сессиясен чакыру турында карар кабул ителде.

Сессия 1997 елның 15 нче октябрендә иртәнге сәгать 9да район хакимиятенең конференц - залында үткәреләчәк. Көн тәртибендә түбәндәге мәсьәләләр каралачак:

1. Район сайлау комиссиясе рәисенең халык депутатларының Октябрь район Советына 13 нче Дальный сайлау округы буенча үткәрелгән сайлау нәтиҗәләре турында хәбәре;
2. Оештыру мәсьәләсе;
3. Халык депутатларының Октябрь район Советы даими комиссияләре составына үзгәрешләр;
4. Аграр мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисен сайлау;
5. Социаль мәсьәләләр буенча даими комиссия эше турында информация;
6. 1997 елның 9 аена район бюджетының үтәлеше турында;
7. 1997 - 1999 елларга ТР Октябрь районы эчке эшләр бүлегендә җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча комплекслы программаны раслау;
8. Октябрь районында халыктан авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алуның барышы турында хәбәр.

Артларында - «Мәскәү»

Октябрь районының Илюткино авылы халкы, бәлки үзләре дә уйламастан, көнбатыш илләре фермерлары белән узышка чыкты. Моннан нәрсә килеп чыгар?

Илюткино авылы яныпбетеп килә торган шәм кебек сүнә бара иде. Нәкъ менә көчле дарулар белән генә тора һәм алар беткәндә үзе дә үлем хәлендә кала торган сырхау төсле.

Хәлнең котылгысызлыгы бөтен нәрсәдә ярылып ята иде: халык йорт салудан, нигез корудан туктады, туйлар бөтенләй булмый башлады, аның каравы, зират юлы такырая торды. Җирле мәктәпне төмамлаучылар кулларына аттестат алу белән койрыкларын да тоттырмыйлар. Авылда җыр тавышы ишетелсә дә, шат күңеллелектән түгел, ә кайгыларын хәмер белән юарга тырышучыларның исерек җырлары гына иде алар.

Хәер, нәрсә дип шатланырга ди соң? Коммунизм турындагы әкиятнең икенчесенә - базар реформалары турындагысына алышынуыннанмы? Шуңа да эшкә хуҗаларча караш турында лыгырдаулар белән берәттән эчкечелек һәм каракльк үскәннән - үсә генә барды. Яртышар ел буе хезмәт хакы күрмәгән, балаларын мәктәпкә озатыр өчен яңа кием дә алырга хәленнән килмәгән кешеләргә ни эшләргә кала соң? Ул чактагы колхоз рәисе Владимир Сайкин хуҗалыкны ничек тә булса таркатмыйча алып барыйм дип җан фәрманга чаба чабуын. Әмма бу очракта ул коралсыз сугышчылар окоптан башларын чыгарырга күркып ятканда сәнәк күтәреп танкка каршы баручы комиссарга охшый. Бәяләр тигезсезлегенең ул кадәрле котыруына юклы - барлы иген-уңышы һәм малларның продуктлылыгы белән нинди хуҗалык каршы тора алсын ди. Гектардан 17 - 20 центнер ашлык үзенә киткән чыгымнарны капларга да чак - чак кына җитә, ә бер сыердан елына 2600 килограмм сөт савуның зыяннан башка әҗере юк.

Һәм шундый көннәрнең берсендә Владимир Николаевич Сайкин таң беленер беленмәстә фермага килеп чыксса, анда дәү генә гәүдәле, күн пәлтә киеп, галстук та таккан бер кешене очрата. Аның районга килгән яңа хакимият башлыгы булуын шунда ук чамалап ала Сайкин. Берара каушап та кала. Сыерлар әбык һәм пычрак булып, абзардагы тирес атна буе түгелмәгәнгә охшап торганда каушамассың ди, бар. Җитмәсә, савым вакыты якынлашып килсә дә, әле бер генә савучы да күренми. Бер дә ашыкмыйлар шул.

«Бетте баш, әләгә икән болай булса», дип уйлап куя әлеккеге министрның катылыгы турында ишеткәне булган Владимир Николаевич. Алай да бик үк коелып төшми.

Ә Сибагатуллин, һич көтелмәгәнчә, рәисне белән тотыбрак алып абзар буйлап барган көйгә хуҗалыктагы хәлләр турында сораштыра башлый. Аннан, уйламаганда - нитмәгәндә:

- Әгәр дә сез хуҗалык исәпле кооперативлар оештырып карасагыз ничек булыр иде икән? - дигән тәкъдим ясап куя. - Ахыр нәтиҗәгә эшли торган иттереп?

Сайкинның кинәт күңеле үсеп киткәндәй була: бу арада үзе дә нәкъ шул турыда гына уйланып йөри ләбаса. Бигрәк тә вакытлы килеп чыкты бит әле болай булгач.

Шуннан башланды да инде. Бәхәсләр дә, җыелышлар, икътисадый исәпләүләр, аңлатулар, өметләндерүләр... Иң катлаулысы нәрсә буламы? Кешеләр дистә еллар буена сәгатьтән сәгатькә генә эшләп күнеккәннәр, ә җае килгәндә, төпкә җигелеп тартучыларның җилкәсендә яшәргә дә каршы түгелләр. Үзгәрешләр, дисциплинаны ныгыту кирәклеге, җиңнәрне сызганып эшли башларга вакыт икәнлеге белән сүздә барысы да килешә кебек, әмма тилегә салынып эленке - салынкы йөргергә гадәтләнгәнлек инерциясен җиңүе ай - һай авыр икән шул.

Башта лидерларны сайлыйлар. Бик тиз үк булмаса да, колхозның элеккеге рәисе, ул чактагы баш агроном Анатолий Гаврилов, баш инженер Иван Петров кооперативларга башлык булырга ризалашалар. Ә инде Владимир Сайкинга бу камытны кимим дип тарткалашып торырга да юк иде: барыбер ничә еллар буе шул авыр йөкне тарта бит инде.

Әллә инде шуннан да ары артка таба чигенергә,юл калмаганга, әллә хакимият башлыгының ярдәмле хуплавы да хәлиткеч роль уйнадымы, өч кооператив башлыгы да эшкә чын-чынлап алындылар.

Башта хуҗалыктагы җирне, төп фондларның: корылмалар, техника, терлек, орлыкның бәясен кабаттан исәпләп чыктылар... Һәм «Москва»да реформа нәкъ әнә шуннан башланды да инде. Ник дисәң, колхоз малын шулай җентекләп күптән санап караганнары юк иде бит инде.

Җирне 5,13 әр гектар исәбеннән пай иттереп бүлделәр. Һәр колхозчы, авылның бюджет сферасында эшләүче һәр кешесе һәм пенсионеры милекчегә әйләнде. Шул хакта таныклыклар әзерләнде.

Тик эшнең иң авыры алда булган икән әле: авыл кешесенә үз милкеннән...баш тартырга булышырга кирәк иде. Әйтик, пенсионерга яки укытучыга ул җир, яки комбайн тәгәрмәче нәрсәгә кирәк ди соң, өстәвенә, алар өчен салым да түлисе бит әле. Аларның барысы да шул милекне әйләнешкә җибәреп файда күрә алырдай кешеләргә генә кирәк бит. Ә колхозда кемнең хәленнән килерлек соң бу? Булса да шул яңабаштан оешкан кооперативлардан гына булырга мөмкин.

Хәлнең җаваплы булуын аңлап, хуҗалык исәпле ул берләшмәләр башлыклары пайчылардан арендага алынган ул җирне дә,милекне дә үзара тигезләп, ә бәхәсле очракларда жирәбә буенча бүләргә килешәләр. Моның шулай максатка ярашлы булуына халыкны да күндерәләр. Җирнең яхшысы да, ташландыгы да кооперативларга тигез тисен дип тырышалар. Терлекләрне исә болай бүлешәләр:Петров кооперативы тулысы белән дуңгыз фермасын ала, калган ике кооператив мөгезле эре терлекләрне бүлешәләр.

Дөрес, башта кешеләрне «бүлешү»дә катлаулылыклар булгалый. Әйтик, ире бер кооперативта, хатыны - икенче, малайлары - өченчесендә килеп чыга. Ул проблеманы да хәл кылалар. Берәүләр үз теләкләре белән бер кооперативтан икенчесенә күчәләр, икенчеләре нинди бүленешкә дә риза булалар.

Төп максат нәрсә була соң? Билгеле инде - кыр һәм фермаларның продуктлылыгын күтәрүгә ирешү, шунсыз матди бөтәюгә өметләнәсе дә юк. Кемдер китереп биргәнне көтеп утырып, үзеңә үзең зыян гына итәчәгеңә күпләр ачык төшенә. Шуңа күрә хәзер алда бер - береңә сылтамыйча да, ялкауларга күз йоммыйча да эшләү бурычы гына тора. Әле бүлешкәндә берәүнең дә алданмавына да инанырга кирәк була. Тау түбәсенә менәргә кузгалыр алдыннан маршрутны анык билгеләп, кирәк булган бар нәрсәне хәстәрләп кую, иптәшләреңнең ышанычлылыгына инану зарур булган шикелле, монда, сүздә генә түгел, ә чынлыкта реформалаштыруга тотынганда да ныклык запасы булдыру кирәк була. Иң элек кешеләрнең аңында, күңелендә.

Әнә шулай итеп «Москва» АКШ һәм башка алга киткән илләрнең фермерлары белән узышка чыга.

Болай дип әйтү һич тә кыланудан түгел. Хуҗалыкларда булганда, крестьянны һәр адымда алдыйлар, аның бар бәласе - сатып алу бәяләренең түбән булуыннан, дип зарланганны ишетергә туры килә. Ә чынлыкта хәзер бәяләр дөнья дәрәҗәсендә бит инде. Һәм икътисад кануннары нигезендә бердәй бәяләр шартларында кем сакчылрак хуҗалык итә һәм яхшырак нәтиҗәләргә ирешә, шул яшәп кала. АКШта, Германия, Англия һәм Франциядә, Канада һәм Бельгиядә гектардан 50 - 60 центнер иген уңышы алу, бер сыердан 6 - 7 мең килограмм сөт саву - гадәти хәл. Һәм моңа югары дәрәҗәдә механикалаштыру нәтиҗәсендә, сан белән түгел, ә эшли белү белән ирешелә. Бездә тулы бер бригада эшләгән эшне аларда гадәттә фермер гаиләсенең ике - өч кешесе башкара.

Базарча үзгәртеп коруларның мантыйгы шундый. Һәм без базар икътисадына курс алганбыз, ирекле төстә товар, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен дә алмашу өчен чикләрне ачканбыз икән, телибезме, теләмибезме, безнең крестьянга хәзер дөнья стандартларына ориентлашырга туры килә.

Хәер, Сайкин, Гаврилов һәм Петровның ул чакта бу турыда уйланып торырга вакытлары булмый - язгы чәчү җитеп килә. Кооператив башлыклары - өчесе дә авыл кешеләре, табигатьне дә, туган якларын да, иген кырын да аңлыйлар һәм яраталар, җиргә чын - чынлап бирелгәннәр. Тик менә бу юлы ул аларга тимер юл буйлап искиткеч зур тизлек белән чаба торган экспресс поездны хәтерләтә: «Чәчү» дип аталган тукталышта шул поездга сикереп менеп утырып өлгерергә кирәк була.

Ә иң яңа тракторларына өч ел, калганнарына 6 - 7 ел, кайсыларын инде күптән гамәлдән чыгарырга вакыт булган, культиваторлар һәм чәчкечләре, кем әйтмешли, менә - менә таралырга торган кооператорларга ул экспресска ничек өлгерергә ди соң? Американың берәр фермерына шундый техника белән чәчү үткәрергә тәкъдим итеп,кара әле син, ул, үзенең кешелек дәрәҗәсен кимсетәләр, дип судка бирер иде.

Әмма Илюткино агайларының Америкада булганнары юк шул, үзләрендәге техниканы андагы белән чагыштыра алмыйлар. Шуңа күрә алар чынлап торып язгы чәчүгә әзерләнәләр, орлык эшкәртәләр, азмы - күпме ягулык запасы туплыйлар, запас частьләр юнәтәләр, минераль ашлама ташыйлар.

- «Мәскәүләләр» бу язда минем теңкәмә тиделәр,- ди «Агрохимсеривс» АҖ генераль директоры Х.Х.Морадыймов.- «Москва» колхозының кайчан да булса бөек кооператорлар ташыган кадәр ашламаның яртысын да кайтарганын хәтерләмим...

«Мәскәүләләр» турында районда бүген күпләр яхшы фикердә. Ә менә ул чакта кооператорларның күңелендә нинди уйлар булган икән соң? Ничек кенә тырышмасыннар, чәчү якынлашкан саен борчылулары көчәя генә төшә аларның. Ник дисәң, исәпләп карау дым каплаудаике смена эшләгән тәкъдирдә дә бу мөһим агрочараны бер атнадан да тизрәк башкарып чыга алмаслыкларын күрсәтә: техникалары шул чамалы гына. Ә бу чәчү вакытында орлыклар инде дымы очкан туфракка ятачак дигәнне аңлата. Әле бит техниканың ватылуы да бар.

- Кара әле, Анатолий, әгәр үзебез тырмага жигелсәк ничек булыр икән,- ди бер көнне Сайкин Гавриловка,- без бик үк карт түгел бит әле.

Анатолий Германович коллегасына шикле генә карап куя. Әмма тегесенең йөзендә ник бер елмаю билгесе булсын.

Шуңа да кооператорларның аларга лизинг буенча, ягъни льготалы шартларда бер ДТ- 75 тракторы бүленүе турындагы хәбәргә ничек сөенгәннәрен әйтеп тору кирәкме икән. Бигрәк тә вакытлы, кирәкле һәм кыйммәтле ярдәм!

Тик тагын бер проблема: бер тракторны ничек итеп өчкә бүләргә соң? Уйлаштылар да, жирәбә салырга булдылар. Трактор Сайкин кооперативына чыкты. Башка кооперативныкылар сукранып карадылар каравын, тик ни хәл итәсең? Гаделлек белән бүленде бит.

Ә тагын өч - дүрт көннән «Москва»га тагын чылбырлы ике, бераздан көпчәкле өч трактор кайтты. Хакимият башлыгы үзенең реформалаштыруга өндәвен әнә шулай ныгытты.

... «Москва»да чәчү вакытында да, урак өстендә дә булырга туры килмәдеме. Мин килгәндә инде соңгы гектарларны суктыралар, салам жыелып беткән диярлек, ә кырларда сөрү агрегатлары эшли иде. Мастерской янында гараж мөдире Анатолий Светкин (ул үзе үк шофер да, слесарь да) иске - москыдан бензин ташу машинасы жыеп ята иде.

Сайкин һәм Гаврилов кооперативлары кырларыннан гектардан 50шәр центнер ашлык чыккан, Петровныкылар 40ар центнердан күбрәк уңыш биргән. Кооператорларның чәчүне дә вакытында башкарып чыгулары, үсемлекләрне минераль ашламалар белән дә вакытында һәм житәрлек күләмдә тукландырулары, чәчүлекләрне чүп үләннәрдән, төрле корткычлардан һәм авырулардан саклау өчен пестицидларны да таба алулары нәтиҗәсе булып тора бу.

- Таптык дип инде, ашламасы да, агу - химикатлары да юлда аунап ятмый,- ди Владимир Сайкин.- Норлат сөт - май комбинаты товар кредитлары биреп булышты.

- Бодай бик уңды,- дип дәвам итә Сайкин.- Элеваторда аны 28 процентттан югарырак жилемсәлелек белән кабул иттеләр.

Ә кыйммәтле бодайга бәя дә югары.

Авырлыкларны жиңү жиңел булмый. Югалтуларсыз гына да бармый эш. Шундый «югалган» сугышчыларның берсе Алексей Богданов белән аның ярымжимерек йорты нигезендә сөйләшеп утырдым мин. К оперативтан август башы да, уракның нәкъ кызган ч гында, иртән эшкә кызма килгәне өчен чыгарганн аны.

- Берни дә әйтерлек түг хәзер эшләмичә, башкал күләгәсендә генә калып бу мый шул, - диде ул үзе хакта.

Аның кебек эшсезл Илюткинода берничә жыел инде. Реформаларны жиңе чыгарга көчләре дә, ру ныклыклары да житмәг аларның. Гаиләсенең ма ди бөтенлеге өчен алшар булып тора торган ах нәтиҗәгә эшләү механиз торларны фидакарь хезмә кә туплый.Чәчүдә дә, урак да көнне - төнгә ялга эшләгәннәр. Берәү дә баш кага салынмаган. Кирәк бу ганда тракторчы үзе үк ащ ламасын да тутырган, ан үзе үк басуга да алып килгә аннары, ашламаны чәчкеч салып тракторын кабызга Күпсанлы урынбасарларда һәм ярдәмчеләрдән, агро номнардан һәм зоотехни лардан арынган кооперати башлыклары умарта корт шикелле эшлиләр - басу әбәт илтергә дә өлгерәлә фермага барып фураж т ратырга, Норлатка бары запас частьлар алып ка тырга да житешәләр. Шу күрә аларның кооператив тагы эш темпына түзә а маганнарны жәлләп шешәгә ябышканнарн үгетләп - мазар торыр вакытлары калмый да. А дан шулай килешенгәч, ко лектив белән саубуллашы га мәжбүр булучылар д үпкәләп маташмыйлар.

Дөрес, рәхәткә чыгы жәннәттә яшәргә ерак эл илюткинолыларга. Коопер торлар жыелган уңышт пайчыларга икешәр центн ашлык һәм берәр тон печән биргәннәр. Анысы начар түгел. Хәер, крестья га жәннәтнең беркайчан буласы юктыр инде ан Кайчан да булса мат бөтенлек белән яши торг чаклар житәр бәлки. Әм моның өчен быел алын һәм күп физик, рухи көч к алынган шушы ритмга кү геп житәргә кирәк булач әле. Алга таба гел шул яшәргә күнегергә кирәк. Ә тагын киеренкелекне бер гына булса да арттыру с рала. Ник дигәндә, безн кооператорларга Америк фермерларына житу өч бик күп кирәк әле.

Уңыш начар түгел аны Ул яктан америкалыл белән тиңләшерлекләре б безнекеләрнең. Тик уңышка «ничек кенә бул да» дип түгел, ә мөмк кадәр азрак чыгымнар бел ирешә башларга кирәк ә

- Әгәр без, властьла крестьянга арка белән б рылмасак, реформаның б рып чыгачагына ышанг нарны ярты юлда ташл калдырмасак, авыл бар бер олы юлга чыгачак,- Октябрь районы хакимия башлыгы Ф.С.Сибагату лин ныклы ышаныч белә Ә без авыл кешесенең өм тен сүндерергә, аларны а дарга теләмибез дә, алд маячакбыз да.

Владимир БЕЛОСКО

(«Республика Татарстан»ның быелгы 24 сентябрь санынан).

Гомерегез заяга узмаган...

Урта Камышлыдан 86 яшьлек Пелагея Кузьминична Левакова район мәдәният йортының шундый зур, якты залында аны да искә алып үтәрләр, аның турында йөрәкләргә үтәрлек сүзләр әйтеп, хатирәләрен яңартырлар дип уйлап та карамагандыр. Аның кебек тыйнак хезмәт кешеләре авылсаен йөзәрләгән бит... Пелагея белән Гурий Леваковларның комсомол - яшьләр туйлары да кичә генә булып үткән кебек әле. Бер - бер артлы өч балалары туды. Тик яшь гаиләнең бәхетле көннәре генә санаулы булган икән шул - дәһшәтле 41 нче ел килде. Гурий шул китүдән югалды. Көн туса нинди дә булса хәбәр көтте аңардан Пелагея. Тик... Иренең үлгән хәбәре сугыш беткәч кенә килде. Кайгысы ничек кенә зур булмасын, сугылып төшмәде Пелагея, бәгыре дә катмады, элеккечә бер вазифадан да баш тартмыйча колхоз эшенә йөрүендә булды. Өч баласына да югары белем бирә алды. Инде бик күп гомер үтсә дә, Пелагея Кузьминична әле дә егәрле, күңеле игелек белән тулы һәм шуңа күрә дә авылдашлары кайгы - шатлыкларын элеккечә үк уртаклашалар аның белән.



1 октябрьдә булган һәм өлкәннәр укенлеген башлап җибәргән бу бәйрәм Пелагея Кузьминична Левакова кебек күпсанлы сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен җылы рухлы вакыйга да булды, фронт юлларын бергә үткән, тылдагы авырлыкларны бергәләп кичергән кордашларга бер очрашып аралашу мөмкинлеге дә бирде, бу көнне тантанага килгәннәрнең, төрле сәбәп белән килә алмыйча калганнарның берсе дә 1 октябрьдә игътибардан да, бүләк - күчтәнәчләрдән дә мәхрүм калмады. Ә бәйрәм тантанасы өлкәннәрне аларның яшьлек чоры җырлары белән очраштырган зур концерттан башланып китте. Берсеннән - берсе матур чәчәк композицияләре белән бизәлгән сәхнәгә яшь башкаручылар гына түгел, ә нигездә ветераннар үзләре күтәрелде - район мәдәният йорты каршындагы «Ветеран» хоры, гомер буе үзешчән сәнгатьтә катнашып килгән һәм инде шактый олыгайсалар да җырга һәм нәфис сүзгә мәхәббәтләре сүрелмәгән Таисия Емельяновна Иванова, Коммунелла Владимировна Изотова, Сания апа Котдусова, Валентин Александрович Комолов һәм башкалар чыкты.

Рәсемнәрдә: район мәдәният йортында үткән бәйрәмнән күренешләр.

Н.АЗИЗОВ фотолары.

Шушы очрашуга дип махсус рәвештә районга Татарстан Республикасы вице - премьеры И.К.Хәйруллин килде. Бер көн элек кенә республиканың шушы катлам кешеләренең социаль мәнфәгатьләрен кайгыртырга чакырылган төрле министрлыклар һәм службалар вәкилләре составында килгән мәгълүмат төркеме дә катнашты бу бәйрәмдә. Кунакларны ипи - тоз һәм чәчәкләр белән каршы алдылар һәм соңгысын вице - премьер шунда ук хатын - кыз ветераннар кулына тоттырды. И.К.Хәйруллин өлкәннәрне бу истәлекле бәйрәм белән котлады, аларга тазалык - саулык, уңышлар, күңел тынычлыгы теләде һәм хөкүмәтебезнең җәмгыятне катлаулы икътисадый үзгәртеп корулар юлыннан алып бару сәясәтен аңлап кабул итүләре өчен рәхмәтен белдерде. Сугыш һәм хезмәт ветераннарының социаль хәле мәсьәләләре һәрвакыт Президент һәм хөкүмәтнең игътибар үзәгендә булуын билгеләп, ул 1 октябрьдән һәм 1 декабрьдән пенсияләрнең минималь күләме арттырылуын һәм Татарстанда иҗтимагый бәяләр күтәрелмәячәген хәбәр итте. Вице - премьер республикада торак пунктларны газлаштыру, халыкны социаль яклау, дару белән тәэмин итү, дәүләтнең кайбер чараларын финанслау белән бәйле проблемаларны да читләтеп үтмәде һәм Пенсия фондының район бүлеге алдына пенсияләрне регуляр түләп бару өчен средстволарны үзвакытында җыю бурычын куйды.

... Бик озакка барды әле ул бәйрәм. Анда өлкәннәргә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның котлау сүзләре дә җиткерелде, сугыш һәм хезмәт ветераннары район Советы рәисе И.У.Гыйләҗев та чыгыш ясады. Бабаларын һәм әбиләрен нәниләр дә котлады. Аннан соң әле фойеда тынлы оркестр көе астында биеп тә әйләнделәр. Ахырдан исә ветераннарны шәһәр ашханәләрендә чәй өстәлләре янында кунак иттеләр.

Т.НАЗАРОВА.

ЯЗГА ОРЛЫК КӨЗДӘН ӘЗЕРЛӘНӘ

Район хуҗалыкларында сабан культуралары орлыкларының сыйфаты

Саннарның беренче баганасы - I, икенчесе - II, өченчесе - III класслы, дүртенчесе - кондициясез орлык (1 октябрьгә тикшертелгәнгә карата процентларда).

«Киекле»	67	33		
Мичурин исем.	81	4	15	
Хафизов исем.	100			
М.Җәлил исем.	58	5	19	17
«Родина»	54	5	18	23
«Игенче»			16	84
«Заветы Ильича»	69		31	
«Алга»	67	33		
«Комбайн»		8	92	
«Әлмәт»		72	28	
«Татарстан»	68	32		
«40 лет Победы»		43	57	
«Таң»	73	27		
«Үрнәк»		24	76	
«Кондырча»	58	13	17	11
Кузнецов исем.	78	22		
«Заря»	34	42	24	
«Чирмешән»	38	23	19	20
Синдряков исем.	100			
«Рассвет»		100		
Якты Күл	34	59	7	
«1нче Май»	100			
Нефтебаза ярд.хуҗ.		73	27	
Шикәр заводы ярд .хуҗ.				
МСО ярд.хуҗ.		59		41
Сөт-май комбинаты ярд.хуҗ.				
«Төрнәс»	2	41	12	45
РСУ ярд.хуҗ.		79		21
«Агрохимсервис» ярд.хуҗ.		40		60
«Дуслык»	80	20		
«Лесная Поляна» Район буенча	40	32	19	9

Киләсе елга сабан ашлыгы орлыкларын үзвакытында тикшертеп куюның мөһимлеген кабатлап торасы юк кебек. Мичурин исемендәге, М.Җәлил исемендәге, Кузнецов исемендәге, «Заря», «Якты Күл», «Дуслык», «Төрнәс», «Алга», «Әлмәт» хуҗалыклары төп чәчүлек фонд орлыклары үрнәкләрен Дәүләт орлык инспекциясенә тулысы белән диярлек китерделәр һәм аларның шактые тикшерелгән дә инде. Әмма чәчүлек материалны бүгенгәчә анализга китереп бетермәгән хуҗалыклар да байтак әле. Хафизов исемендәге, «1 нче Май» хуҗалыкларында, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында тикшертелгән орлык аз әле, ә шикәр заводы һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларыннан бүгенгәнчә бер генә үрнәк тә китерелмәгән көе. Шуңа күрә дә район буенча сабан ашлыгы орлыкларының төп фондының 70 проценты гына тикшертелгән көе. Әле бит чәчүлек материалны инспекциядә тикшертү белән генә дә эш бетми - аны тиешле кондициягә җиткерү өчен шактый көч түгәргә, аларны кырык кат иләктән үткәрергә туры килергә мөмкин. Һәрхәлдә, чәчүлек орлыкның тикшертелгән кадәресенең сыйфаты шуңа ишарәли. Таблицада китерелгән мәгълүматлар барлык орлыкларның уртача күрсәткечләре генә һәм әле анысы да уйландырырлык. Ә инде аерым культураларга килсәк, хәл тагы да борчулы. Әйтик, «Комбайн» һәм «Үрнәк»нең бодай орлыгы тулысы белән, «Әлмәт»нең 60 процента өченче класслы, МСО һәм «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыкларыныкы чисталыгы буенча тулысынча, «Төрнәс»тә 70 процента кондициясез. Ә бит орлык хәзерләү эшенә тиешле игътибар биргән Мичурин исемендәге, Кузнецов исемендәге хуҗалыкларда бодай орлыгы башкалардагыга караганда чагыштырмача күп булса да, фәкать I класслы, «Алга», «Дуслык», «Заря"да да бу яктан хәл әйбәт. Мичурин исемендәге, «Дуслык» һәм Синдряков исемендәге хуҗалыкларда борчак, соңгысында һәм «Чирмешән»дә солы орлыгы I класслы гына. Кызганычка каршы, быел борчак орлыгының сыйфаты гомумәндә мактанырлык түгел, тикшертелгән кадәренең яртысыннан артыграгы II класслы, биштән бере диярлек, шул исәптән М.Җәлил исемендәге, «Игенче», Родина», «Төрнәс», «Кондырча» һәм «Чирмешән»дә кондициясез, өстәвенә аның яртысы чисталыгы буенча, ә «Родина»да брухус буенча яраксыз. «Заря», «Якты Күл», Мичурин исемендәге хуҗалыкларда солының тикшертелгәне III класслы гына, күп хуҗалыкларда ул бары II генә класслы. Арпа орлыгы белән дә мактанырлык түгел: тикшертелгән орлыкның яртысына якыны III класслы булып, фәкать I класслы орлык әлегә «Киекле», Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге һәм «1 нче Май» хуҗалыкларында гына бар. Дөрес, солы һәм арпаның тикшертелгән кадәргесе арасында кондициясез орлык табылмаган, әмма моңа карап тыныч-ланырга юк, чөнки, инде әйткәнебезчә, чәчүлек материалны I, һич югы II класс таләпләренә җавап бирердәй хәлгә китерү өчен шактый тырышырга туры киләчәк әле.

Гомумән алганда, быел сабан ашлыгы орлыкларын салып кую белән күп кенә хуҗалыкларда тыныч-ланып калдылар һәм орлык калибрлау кебек мөһим эшне соңга калдыру, бу мәсьәләгә авыл хуҗалыгы идарәсенең игенчелек бүлеге тарафыннан да контроль җитмәү, дәүләт орлык инспекциясендә дә елдагы таләпчәнлек күрсәтелмәүнең нәтиҗәләре күз алдында. Сабан ашлыгы орлыкларын салкыннарга кадәр, әле кузгатырга мөмкин булган чакта эш итеп куюны бик ашыктырасы бар. Әле бит хуҗалыкара алмашу, башка чыганаклардан орлык эзләү мәшәкатьләре дә булмас диеп булмый һәм ул эшне хәзер, көздән башкарып куйганда яхшы.

Безнең календарь

Празат Исәнбәткә - 70 яшь

Халык язучысы Нәкый ага Исәнбәт гаиләсендә туып үскән Празат Исәнбәт балачактан ук сәнгать, әдәбият белән кызыксына. Рәссам булырга әзерләнә, ә шулай да театр юлын сайлый. 1949 елда Мәскәү театр институтын (ГИТИС) тәмамлап, Г.Камал исемендәге театрда сабакташлары Р.Бикчәнтаев,Д.Ильясов, Ш.Әсфәндиярова һәм башкалар белән бергә, үзен талантлы артист итеп таныта. Шул ук уку йортында режиссерлыкка укып кайтканнан соң, 1957 елдан Академия театрында яңа иҗат эшчәнлеген башлый.

40 елда куелган 70ләп спектакль талантлы режиссерның тормышы ул; тирән белеме, иманы, заман таләпләрен нечкә сиземләве, театрга, артистларга булган олы мәхәббәте, искиткеч тырышлыгы нәтиҗәсе.

«Галиябану», «Таһир - Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», «Татар хатыны ниләр күрми», «Суган суфые», «Чамасына күрә чарасы», «Кол» әсәрләрен искә алу да режиссерның иҗат колачы киң булуын күрсәтә.

П.Исәнбәт соңгы елларда Г.Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясен, «Алдым, бирдем», «Җан Баевич» комедияләрен сәхнәләштереп, хаксызга онытылган драматургны халкыбызга кайтарды.

Луара ШАКИРҖАНОВА.

Фаҗигаләр азрак булыр иде...

Быелның 19 июлендә ГАЗ - 52 автомашинасы руле артына исерек хәлдә утырган шофер Ә.М.Шәрапов Норлат - Биккол юлында 13 яшьлек җәяүле малай Т.Әхмәтшинны таптатты һәм тегесе җәрәхәтләрдән үлде.

Милиция хроникасының коры гына бу юллары артында кеше гомере дә, фаҗигале үлем дә бар. Юлда балаларның имгәнүе - заманыбызның иң үкенечле чирләреннән. Моны булдырмау максатыннан күпсанлы чаралар күрелсә дә, ул проблема һаман да кискен булып кала килә әле. Югыйсә, сәбәпләре дә аңлаешлы кебек һәм аларны санап чыгуы да авыр түгел: болар - иң гади кагыйдәләрне дә белмәү яки белеп тә үтәмәү. Бәлки кайбер ата - аналар бу мәсьәләгә җитди нәрсә дип карамый торганнардыр. Аннары, бер -бер хәл була калса да, мине ходай саклар әле дигән төслерәк уйлау да бар. Ә бит статистикага мөрәҗәгать итсәк, Татарстан Республикасында гына да сигез айда балалар катнашы белән 400ләп юл -транспорт вакыйгасы килеп чыгып, аларда 39 бала үлгән. Безнең районда да андый өч вакыйга булды. Аларның берсе турында сез беләсез инде. Ә 27 февральдә 1985 елгы Л.Максимов машина юлына йөгереп чыгып руль артында Җәлалов булган ЗИЛ машинасы тарафыннан тапталды һәм баш мие кузгалган хәлдә район үзәк шифаханәсенә китерелгән иде. Өченче очрак 30 апрельдә Мамык авылында булды. 10 яшьлек Ю.Силаева автобус артыннан юлга йөгереп чыгып КамАЗ машинасы астына эләкте һәм уң боты сынып шифаханәгә китерелде.

Профилактика эше максатчан төстә, планлы рәвештә һәм эзлекле алып барылганда нәтиҗәләрнең дә әйбәт булуы мәгълүм. Юл йөрү кагыйдәләрен үтәү зарурлыгы балаларның канына сеңәргә тиеш. ГАИның юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фонды район мәгариф бүлеге белән берлектә 1997 - 98 нче уку елына балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү буенча чаралар планын эшләде. Анда төрле конкурслар, уеннар, викториналар, лекцияләр һәм әңгәмәләр дә үткәрү каралган. Әйтик, август уртасында профилакторийдагы сәламәтләндерү лагерында юл хәрәкәте кагыйдәләрен белү көне үткәрелде. Балалар ГАИ начальнигы Х.В.Әюпов белән очраштылар, рәсемнәр конкурсы булды, анда җиңүчеләргә призлар һәм истәлеккә фоторәсемнәр бирелде, ә барлык балалар да туңдырма белән сыйланды. Кем белә, формаль булмаган мондый чаралар никадәр күбрәк булса, балаларның юлда имгәнүләре шулкадәр азаер иде бәлки.

Г.ГЫЙММАЛЕТДИНОВА.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Иске Әлмәт авылында яшәүче ***Нурия Мәхмүт кызы Җамалетдиновага*** *8 октябрьдә 60 яшь тула. Аны чын күңелдән юбилее белән тәбрик итәбез, корычтай сәламәтлек, бәхет телибез.*

Бакчаларда кошлар сайрап туймый
Сине котлап туган көнеңдә.
Изгелекләр генә терки булыр
Фәрештәләр синең иңеңдә.
Син бит, әнкәй безне үстергәнсең,
Йокламыйча төнге йокыңны.
Төннәрендә безне көтә идең
Сүндермичә якты утыңны.
Тормыш иптәше, улы, килене, кызлары, кияве, оныклары.

Югары Норлат авылында яшәүче безнең өчен бик кадерле, зур ихтирамга лаек булган әтиебез **Сәлим Шакир улы Фәхретдиновны** 60 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Киләчәк көннәренең дә сау - сәламәт булып, шатлык - куанычта үтүен, гаилә бәхете, әни белән бергәләп, тигез озын гомер кичерүләрен телибез.

Чәчләреңне, әткәй, чал басса да,
Күңелең иркен, һаман яшь әле.
Җаның тыныч, төнең таза булсын,
Кайгы - хәсрәт күрми яшәле.

Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, кияүләрең, оныкларың.

Белдерүләр

Документларга ашыгыч фото

Хөрмәтле шәһәрләләр!

«Экспресс - фото» фотосалоны сезне яңа төр хезмәтләрдән файдаланырга чакыра.

- документларга (таныклык, пропуск, виза, бәлешмә һ.б.) 2 минут эчендә кара - ак һәм төсле фотографияләр.

Фотографияләр размеры - 2,5 х 3,5 һәм 3,5 х 4,5 см. (Евростандарт). 1,2 һәм 4 сурәт ясарга мөмкин. Әлеге форматларның теләсә кайсысында 4 фотография бәясе:

12000 сум - ак - кара фотография өчен;

16000 сум - төсле фото өчен.

Лицензия номеры - Б 97054163, Б 97054162.

Эш вакыты - 9.00дан 18.00га кадәр, төшке ял - 13.00 - 14.00да. 1997 елның 1 августыннан ялсыз.

Шәһәр һәм район халкы игътибарына:

«Экспресс - фото» фотосалоны яңа төр товарлар һәм хезмәтләр тәкъдим итә:

Компьютерлар:

586 AMD K - 5 - 133, 256 Kb, 8Mb, 1Gb, 1.44, 1Mb, 0.28 5 130 000 сум.

Intel Pentium - 150, 256 Kb, 8Mb EDO, 1Kb, 1.44, 1Mb, 0.28 CD - ROM 6s^ Sound Card ESS 1868 6 130 000 сум.

Intel Pentium - 200, 512Kb , 16Mb EDO, 2.1Gb, 1.44, 0.28

2Mb S3 Trio 64V + EDO, CD - ROM 8s, Sound Blaster 16

Ксерокс Canon FC - 230, формат А 4 7 210 000 сум.

3 240 000 сум.

Моннан тыш:

гарантияле һәм постгарантияле стандарт булмаган конфигурацияле компьютер техникасына хезмәт күрсәтү, заказ буенча кайтару, компьютер һәм оргтехникага техник хезмәт күрсәтү, ксерокслар өчен картриджлар тутыру, принтерларга тасмалар буяу, ПЭВМнарга комплектлаучы детальләр кую, алыштыру, компьютерларны модернизацияләү, программа кую, вируслардан профилактикалау, дәвалау, телефакслар, факсмодемнар һ.б кую буенча консультация, компьютер челтәрләрен проектлау, кую.

Түләү формасы - күчерү юлы белән, кулдан түләп, бартер мөмкин.

Кирәкле техниканы, әзерлекле белгечләрдән ярдәм һәм консультация алырга яки сезгә кирәкле товарларга заказ бирергә теләүчеләр өчен адрес:

Норлат шәһәре, К.Маркс ур., 51 а йорт.

«Фламинго» кибете ачылды. Яңа өйләнешүчеләр һәм яңа туган балалар өчен товарларны түбәндәге адрес буенча алырга мөмкин:

Линейная ур., тимер юл вокзалы артында. Бәяләр - арзан. Лицензия - Б - 97 № 095838.

АБОНЕНТЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Чистай - Норлат участогында кабель элемтә линиясен реконструкцияләү сәбәпле 1997 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы район үзәкләренә чыгу кыенлаша. Торгызылу турында өстәмә хәбәр итәрбез.

Район элемтә узелы администрациясе.

ТӨРЛЕСЕННӘН

Михайлов Геннадий Николаевич исеменә документлар табучыны бүләк бәрабәренә иясенә (яңа базарда) кайтарып бирүләрен сорыйбыз.

***

Йосыпов Сәлихҗан Таһирҗан улы исеменә документлар табучыны бүләк бәрабәренә РСУга кайтарып бирүләрен сорыйбыз.

***

Шәһәр үзәгендәге 2 бүлмәле фатир өстәмә түләп 1 бүлмәлегә алыштырыла яки сатыла. Тел.: 2 - 26 - 21.

Идел Буе региональ наркология үзәге

Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру. ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

Бездә генә!

Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рәхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!

Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

Уллары **Илназның** фаҗигале вафат булуы сәбәпле Минвазыйх һәм Сурия Идрисовларның авыр хәсрәтен уртаклашабыз.

Нуретдиновлар гаиләсе.

Белдерүләр

Сатабыз

Первомайская ур., 24 адресы буенча йорт. Кичке 6 дан соң мөрәҗәгать итәргә.

***

Норлат сәүдә базасы түмәрләп һәм ваклап сата: тавык ботлары - килограммы 11100 сум.

Ульяновск фабрикасы ассортиментында кондитер әйберләре, «Джойта», свежий балык.

Шифер - 19000 сум; рубероид - 64000 сум; 500 граммлы «Лотос» порошогы - 4000 сум; сүс - 320000 сум; цемент - 30000 сум; май, шикәр комы, югары сортлы он белән бартер мөмкин;

«Тоник» эчемлеге - 3650 сум.

***

ГАЗ - 69 машинасына резина комплекты. Тел.: 2 - 15 - 75.

***

3 бүлмәле фатир. Московская ур., 5 - 45.

***

Йорт. Адрес: Лобачевский ур., 75.

***

«Алмалык» бакчачылык ширкәтендә дача, вагоны бар. Адрес: Победа ур., 25.

***

Югары Норлатта яңа йорт (газ, су). Тел.: 2 - 25 - 47.

***

Савым сыеры. Мамык авылында Лесиннарга мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 4 - 13 - 45.

Япмалы әрҗәле УАЗ - 3303 - 024, яңа белешмә - система, тизлек тармасы белән кулланылышта булган ГАЗ - 52 двигателе. Адрес: Дружба ур., «Яшьлек» кафесының беренче катында «Ашамлыклар» кибете.

Алмаштырабыз

Кормыш микрорайонындагы 3 бүлмәле фатирны - 2 һәм 1 бүлмәләләргә (тимер юлчылар, шикәрчеләр микрорайоннарыннан тәкъдим итмәскә). Адрес: Совет ур., 127 - 1, кичке 5 тән соң.

***

Кама Аланында аз гаиләләләр өчен фатир - Норлатта шундый укка. Тел.: 2 - 32 - 35.

Эшкә чакырабыз

«Норлатнефть» НГДУсы технологик транспорт идарәсе конкурс нигезендә стажы 5 елдан да ким булмаган кешеләрне түбәндәге вазифаларга чакыра:

гараж начальнигы, колонна механиклары, техниканы линиягә чыгару буенча автотранспорт чаралары контролерлары, автомобиль краннары машинистлары. Түләү - штат расписаниесе нигезендә.

ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Гарантия белән ашыгыч аяк киемнәре ремонтлау. Без сезне тимер юл клубы бинасында 9.00дән 18.00гә кадәр көтәбез.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.